**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
Балык бистэсе
муниципаль районы
Корноухово авыл жирлегенен
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
422644, Корноухово,
Совхоз урамы, 3

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
Рыбно- Слободский
муниципальный район
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
Корноуховского сельского поселения
422644, Корноухово,
ул. Совхозная, 3

Тел.: (84361) 27205, факс: (84361) 27205, e-mail:Kuh.RS @tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** КАРАР

2022 елның 31 гыйнвары Корноухово авылы № 4

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Корноухово авыл җирлегендә җирләү (мәет күмү) буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 06.10.2003 ел,131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм “Җирләү һәм җирләү эше турында” 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, “Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында” Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары нигезендә, КАРАР БИРӘМ:

1. 2022 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Корноухово авыл җирлегендә җирләү һәм җирләү эше буенча хезмәтләрнең, гарантияле исемлеге нигезендә 6964,68 сум күләмендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын , кушымталар нигезендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Корноухово авыл җирлегенең махсус мәглъүмат стендларында урнаштырырга: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Корноухово авылы, Совхоз урамы, 3 йорт; Чирмешан авылы, Советлар урам, 21 йорт; Зюзино авылы, Үзәк урам, 6 йорт; Наумово авылы, Наумово урамы, 3 йорт адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

3.Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Корноухово авыл җирлеге башлыгы Г.С Гумашян

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КОРНОУХОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1634005160
КОРНОУХОВО АВЫЛ ЖИРЛЕГЕНЕҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Корноухово авыл
җирлеге
Башкарма комитетының
2022 елның 31 гыйнварындагы
4 номерлы карарына
кушымта №1

**Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районының Корноухово авыл җирлегендә
2022 елның 1 февраленнән җирләү (мәет күмү) буенча хезмәтләрнең
гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган
хезмәтләрнең бәясе (хакы)**

| Хезмәтләрнең аталышы | Хезмәтләрнең бәясе (хакы) (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Табутны һәм җирләү өчен зарури башка әйберләрне бирү һәм китерү | 2646,95 |
| 3. Мәетне (мәрхүмнең җәсәден) зиратка (крематорийга) күчерү (алып бару) | 997,28 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3320,45 |
| Җәмгысе: | 6964,68 |

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Корноухово авыл
җирлеге
Башкарма комитетының
2022 елның 31 гыйнварындагы
4 номерлы карарына
кушымта №2

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Корноухово авыл җирлегендә ире (хатыны), якын туганнары, бүтән туганнары яисә мәрхүмнең законлы вәкиле булмаганда яки алар тарафыннан мәет күмү гамәлгә ашыру мөмкин булмаганда яисә җирләү бурычын үз өстенә ала торган башка зат булмаганда, мәет күмү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге буенча түләүсез нигездә (бушлай) күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясе (хакы)**
**2022 елның 1 февраленнән**

| Хезмәтләрнең аталышы | Хезмәтләрнең бәясе (хакы) (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Мәетне кәфенләү | 500 |
| 3. Табутны һәм җирләү өчен зарури башка әйберләрне бирү һәм китерү | 2146,95 |
| 4. Мәетне (мәрхүмнең җәсәден) зиратка күчерү (алып бару) | 997,28 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3320,45 |
| Җәмгысе: | 6964,68 |